ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 март 2018 ел. № 1692

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль адреслы программага үзгәрешләр кертү турында

Башкарма комитетның 2017 елның 18 маендагы 3058 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль адреслы программаны актуальләштерү максатында, күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге үзгәрү, күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау сроклары үзгәрү сәбәпле, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2017 елның 18 маендагы 3058 нче карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 25 декабрендәге 8078 нче карары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль адреслы программага, аны кушымтада каралган редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастыруны һәм «Интернет» челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә әлеге карарны торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Управление дело-производством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Башкарма комитетның
2018 елның 29 мартындагы
1692 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль адреслы программа

Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль адреслы программа (алга таба – Программа). |
| Программаны эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Торак кодексы;<br>Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасындагы күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ санлы Законы (алга таба – Закон). |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе. |
| Программаны эшләүчеләр | 1) Яр Чаллы шәһәренең идарәче компанияләре;<br>2) Яр Чаллы шәһәренең район хакимиятләре;<br>3) Генподрядчы оешмалар;<br>4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе. |
| Программаның максатлары | 1) шәһәрнең күп фатирлы йортларындагы гомуми мөлкәткә үз вакытында һәм сыйфатлы капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итү;<br>2) энергия ресурсларын куллануның энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү;<br>3) торак-коммуналь хуҗалыгы сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсен күтәрү. |
| Программаның бурычлары | 1) халыкка капиталь ремонт үткәрү сроклары, төрләре, күләмнәре һәм кагыйдәләре турында хәбәр итү;<br>2) торак фондның техник торышын анализлау;<br>3) энергетика нәтиҗәлелеге технологияләрен кертү;<br>4) торак фондның эстетик җәлеп итүчәнлеген арттыру;<br>5) халыкның аз мобильле төркемнәре өчен уңайлы шартлар тудыру;<br>6) куркынычсыз яшәү шартларын тәэмин итү;<br>7) чыдам материаллар һәм ресурс саклау технологияләрен кулланып капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник карарлардан һәм комплекслылыктан файдалану. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2018-2043 еллар |

<table>
<tr><td rowspan="7">Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="2">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2018 ел</td><td>2019 ел</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>267 347 000,00</td><td>267 347 000,00</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>303 652 750,00</td><td>297 745 612,00</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>839 536 966,64</td><td>673 064 936,51</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1 410 536 716,64</td><td>1 238 157 548,51</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтәлгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="3">1) 2019 елга 249 йортта файдалану күрсәткечләрен яхшырту;<br>2) 2019 елга 109 йортта энергетика нәтиҗәлелеге классын күтәрү;<br>3) гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау мәсьәләләре буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре санын киметү.</td></tr>
<tr><td>Программаның тормышка ашырылуын контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="3">Программаның тормышка ашырылуын контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.</td></tr>
</table>

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

## 1. Проблеманың актуальлеге

Әлеге Программаны кабул итүнең актуальлеге күп кенә социаль-икътисадый факторларга бәйле. Яр Чаллы шәһәре торак фондының үзенчәлеге булып аны чагыштырмача бер үк вакытта файдалануга тапшыру тора. 70-80 нче елларда шәһәрнең актив төзелеше чорында төзелеш комплекслап алып барылды. Төзелеш кыйммәтен киметү өчен типовой проект карарлары кабул ителде. Исәп-хисапка төзелеш масштабын арттыру белән инженерлык челтәрләренә йөкләмә арттыру үзенчәлекләре кабул ителмәде, модернизацияләү мөмкинлеге тудырылмады. Төзелешнең югары темплары төзелеш сыйфатында негатив чагылды.

80 нче еллар ахыры 90 нчы еллар башында социаль-икътисадый кризис һәм дәүләтнең тотрыксыз эчке сәяси торышы күп фатирлы йортларның техник файдалану дәрәҗәсенә тәэсир итте. Биналарның аерым конструктив элементларыннан файдалану срокларына карата норматив актлардагы таләпләр үтәлмәде, бары тик авариягә бәйле ремонт кына үткәрелде. Капиталь ремонт, модернизация программасы булмады. Халыкны дәүләт тарафыннан финанслау булмау торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсенең финансланып бетмәвенә китерде. Алай гына да түгел, хосусыйлаштыру игълан ителгән һәм милекчелек тибы дәүләтнекеннән шәхсигә алмаштырылганнан соң, кризис чорында торак-коммуналь хезмәтләр өчен халыктан алына торган түләүләр сизелерлек кимеде. Закон нигезендә дәүләт, кирәк очракта, хосусыйлаштырылырга тиешле торакны капиталь ремонт белән тәэмин итәргә тиеш. Шуңа карамастан, капиталь ремонт үткәрү кирәклеген билгеләү тәртибе процессуаль рәвештә беркетелмәде. Торак тикшерү акты һәм яшәүчеләрнең ризалыгы буенча тапшырылды. Энергетика ресурсларының, җылылык йөрткечнең, суның түбән сыйфаты күп фатирлы йортлардагы инженерлык челтәрләренең тиз тузуына йогынты ясаучы өстәмә фактор булып торды.

Бүгенге көндә торак-коммуналь хезмәтләр сыйфатына, экономия, экология һәм эргономиягә карата таләпләр үзгәрде. Россия базарында заманча энергетика нәтиҗәлелеге материаллары һәм җиһазлары барлыкка килде, моңа кадәр хәл ителмәслек проблемаларны бетерү өчен технологик карарлар эшләнде. Торак законнарының яңаруы торак-коммуналь өлкәне финанслауның яңа чыганакларын барлыкка китерде.

Шулай итеп, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, тиешле комфортны һәм тиешле яшәеш иминлеген тәэмин итү өчен торак урыннарның дәрәҗәсен заманча шартлар, технологияләр һәм таләпләргә туры китерү таләп ителә.

## 2. Төп максатлар һәм бурычлар, тормышка ашыру сроклары

Капиталь ремонт Программасының төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Күп фатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә үз вакытында һәм сыйфатлы итеп капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итү. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куела:

- капиталь ремонт үткәрү сроклары, төрләре, күләмнәре һәм кагыйдәләре турында халыкның хәбәрдар булуын арттыру;
- торак фондның техник торышын анализлау.

2) Энергия ресурсларын куллануның энергетик нәтиҗәлелеген күтәрү.
Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурыч куела:

- энергетика нәтиҗәлелеге технологияләрен һәм материалларын кертү.

3) Торак-коммуналь хезмәтләр сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсен күтәрү.
Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куела:

- Торак фондның эстетик җәлеп итүчәнлеген арттыру;
- Халыкның аз мобильле төркемнәре өчен уңайлы шартлар тудыру;
- Куркынычсыз яшәү шартлары белән тәэмин итү.

Программа 2018-2043 еллар дәвамында тормышка ашырыла.

Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чаралары буенча финанслау Программага 1 нче кушымтада күрсәтелде.

## 3. Программа чаралары

Билгеләнгән бурычларны үтәү өчен Программаның түбәндәге төп чаралары билгеләнә:

1. Күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча түбәндәге хезмәтләрне һәм (яки) эшләрне башкару:

йорт эчендәге электр-, җылылылык-, су, газ белән тәэмин итү, суны җибәрү инженерлык системаларын ремонтлау яки алмаштыру, шул исәптән торак бүлмәләрдәге җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитария-техник җиһазларны ремонтлау яки алмаштыру;

файдалану өчен яраксыз дип танылган лифт җайланмасын ремонтлау яки алмаштыру, лифт шахталарын ремонтлау, лифтларны диспетчерлаштыру системасы белән җиһазландыру;

түбәләрне ремонтлау, шул исәптән җилләтелми торган түбәне җилләтелә торган итеп үзгәртү, түбәгә чыгу урыннары булдыру;

күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә караган подвал бүлмәләрен ремонтлау;

фасадларны җылыту һәм ремонтлау, халыкның аз мобильле төркемнәре өчен күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә керү мөмкинлеген тәэмин итү максатында подъездларга керү урыннарын пандуслар һәм баскычларны ике яктан да рәшәткәләр белән җиһазландыру;

коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурсларны куллануны исәпләү буенча коллектив (гомуми йорт) приборларын һәм шундый ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) куллану белән идарә итү һәм җайга салу узеллары урнаштыру яки алмаштыру;

күп фатирлы йортның фундаментын ремонтлау;

күп фатирлы йорттагы подъездларны ремонтлау;

күп фатирлы йортта энергетик тикшерүләр үткәрү;

проект документларына дәүләт экспертизасы эшләү һәм үткәрү (шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон нигезендә проект документларын әзерләү таләп ителгән очракта);

төзелеш контролен гамәлгә ашыру;

күп фатирлы йортның янгыннан саклау системасын ремонтлау;

күп фатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү;

күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәт составына керми торган, күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәт составындагы корылмаларны һәм инженерлык системаларын капиталь ремонтлау буенча эшләр башкарганда ремонтлана (алмаштырыла) торган конструктив һәм инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре нәтиҗәсендә демонтажланган яки җимерелгән мөлкәт өлешен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерү;

күп фатирлы йортлардагы коммуналь ресурсларны куллануны исәпләү буенча коллектив (гомуми йорт) приборлары урнаштыру (алмаштыру).

Күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр үткәрү яхшыртылган эксплуатация характеристикаларына ия чыдам һәм экономияле материаллар кулланып гамәлгә ашырыла.

2. Программаны мәгълүмати тәэмин итү, үткәрелә торган процедураларның халык өчен аңлаешлы, ачык булуын түбәндәге юл белән тәэмин итү:

Программаны тормышка ашыру барышын район массакүләм мәгълүмат чараларында (вакытлы басмаларда – газеталарда, журналларда, шул исәптән электрон

басмаларда; радио һәм телевидение каналларында) регуляр яктырту;

торак-коммуналь хуҗалыгын реформалаштыру һәм капиталь ремонт үткәрү мәсьәләләрен яктырту өчен махсус теле- һәм радиопрограммалар булдыру;

Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтын актуаль хәлдә тоту;

торак-коммуналь хуҗалыгын реформалаштыру һәм капиталь ремонт үткәрү мәсьәләләре буенча тематик методик һәм белешмә материаллар чыгару һәм тарату;

гражданнарга күп фатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкаруның планлаштырыла торган сроклары турында торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм торак-төзелеш кооперативлары һәм идарәче оешмалар тарафыннан мәгълүмат җиткерү (Программага кертелгән күп фатирлы йортның һәр подъездында урнашкан белдерүләр такталарында яки мондый йорт урнашкан җир участогы чикләрендә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтларында (булган очракта) тиешле мәгълүмат урнаштыру).

Программага. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күп фатирлы йортлардан тыш, Прогорамманың 2 нче кушымтасында каралганча Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан барлык күп фатирлы йортлар керә.

Күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чираты Законда күрсәтелгән критерийлар нигезендә Программада билгеләнә.

## 4. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны тормышка ашыру максатларында Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан өч ел срокка Программаны тормышка ашыру буенча кыска вакытлы (ел саен төзелә торган) планнар (алга таба – Программаны тормышка ашыру буенча кыска вакытлы планнар) раслана.

Шулай ук түбәндәгеләр үткәрелә:

1) торак милекчеләрәре вәкилләренең ел саен үткәрелә торан җыелышлары;

2) техник торышны анализлау һәм капиталь ремонт программасы планына төзәтмәләр кертү ихтыяҗларын ачыклау өчен биналарга ел саен көзге һәм язгы техник тикшерү үткәрү;

3) гамәлдәге закон таләпләре нигезендә квалификацион сайлап алу һәм аукцион процедурасы;

4) төзү-монтажлау эшләре үткәрү;

5) башкарылган эшләрне кабул итү.

## 5. Программаны тормышка ашыру этаплары

| | |
|---|---|
| 1 этап | 01.01.2018-31.12.2018 |
| 2 этап | 01.01.2019-31.12.2019 |
| 3 этап | 01.01.2020-31.12.2020 |
| 4 этап | 01.01.2021-31.12.2021 |
| 5 этап | 01.01.2018-31.12.2022 |
| 6 этап | 01.01.2018-31.12.2023 |
| 7 этап | 01.01.2018-31.12.2024 |
| 8 этап | 01.01.2018-31.12.2025 |
| 9 этап | 01.01.2018-31.12.2026 |
| 10 этап | 01.01.2018-31.12.2027 |
| 11 этап | 01.01.2018-31.12.2028 |
| 12 этап | 01.01.2018-31.12.2029 |
| 13 этап | 01.01.2018-31.12.2030 |

| | |
|---|---|
| 14 этап | 01.01.2018-31.12.2031 |
| 15 этап | 01.01.2018-31.12.2032 |
| 16 этап | 01.01.2018-31.12.2033 |
| 17 этап | 01.01.2018-31.12.2034 |
| 18 этап | 01.01.2018-31.12.2035 |
| 19 этап | 01.01.2018-31.12.2036 |
| 20 этап | 01.01.2018-31.12.2037 |
| 21 этап | 01.01.2018-31.12.2038 |
| 22 этап | 01.01.2018-31.12.2039 |
| 23 этап | 01.01.2018-31.12.2040 |
| 24 этап | 01.01.2018-31.12.2041 |
| 25 этап | 01.01.2018-31.12.2042 |
| 26 этап | 01.01.2018-31.12.2043 |

## 6. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруның ахыргы нәтиҗәсе булып торак фонд сакланышын тәэмин итү өлешендә халык инициативасы үсешенең уңай динамикасы һәм күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондын формалаштыру өлешендә торак милекчеләре инициативасының үсеше торырга тиеш.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә түбәндәгеләр көтелә:

- торак фондның куллану сыйфаты саклану дәрәҗәсен арттыру;
- күп фатирлы йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар эшләп торуның ышанычлы булу дәрәҗәсен арттыру;
- куркынычсыз һәм уңайлы яшәү шартлары тудыру;
- шәһәр торак фондын файдалану нәтиҗәлелеген исәпләү.

Күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру түбәндәге социаль-икътисадый нәтиҗәләргә ия була:

- йортларның техник торышын яхшырту;
- күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондын формалаштыру өчен торак милекчеләренең акчаларын җәлеп итүгә мөмкинлек бирүче икътисадый механизм булдыру;
- торак-коммуналь комплексын реформалаштыруны активлаштыру.

## 7. Финанслау күләме һәм чыганаклары

| Финанслау чыганаклары | Финанслау акчалары. барлыгы, сум | |
|---|---|---|
| | 2018 ел | 2019 ел |
| Россия Федерациясе бюджеты акчалары | - | - |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчалары | 303 652 750,00 | 297 745 612,00 |
| Шәһәр бюджетыннан акчалар | 267 347 000,00 | 267 347 000,00 |
| Башка чыганаклар (торак милекчеләре ширкәтләре. торак кооперативлары. торак төзелеше кооперативларының яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларының яисә күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләренең акчалары) | 839 536 966.64 | 673 064 936,51 |
| Барлыгы | 1 410 536 716.64 | 1 238 157 548,51 |

8. Муниципаль программа нәтиҗәлелеген анализлау

| Т/с | Бурычның, чараның исеме | Үтәлү сроклары | Эшчәнлек нәтиҗәләренең күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Фактик зурлык | Тайпылыш |
| 1 | Капиталь ремонт 2018 | 01.01.2018-31.12.2018 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 2 | Капиталь ремонт 2019 | 01.01.2019-31.12.2019 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 3 | Капиталь ремонт 2020 | 01.01.2020-31.12.2020 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 4 | Капиталь ремонт 2021 | 01.01.2021-31.12.2021 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 5 | Капиталь ремонт 2022 | 01.01.2018-31.12.2022 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 6 | Капиталь ремонт 2023 | 01.01.2018-31.12.2023 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 7 | Капиталь ремонт 2024 | 01.01.2018-31.12.2024 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 8 | Капиталь ремонт 2025 | 01.01.2018-31.12.2025 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 9 | Капиталь ремонт 2026 | 01.01.2018-31.12.2026 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 10 | Капиталь ремонт 2027 | 01.01.2018-31.12.2027 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 11 | Капиталь ремонт 2028 | 01.01.2018-31.12.2028 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 12 | Капиталь ремонт 2029 | 01.01.2018-31.12.2029 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 13 | Капиталь ремонт 2030 | 01.01.2018-31.12.2030 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 14 | Капиталь ремонт 2031 | 01.01.2018-31.12.2031 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 15 | Капиталь ремонт 2032 | 01.01.2018-31.12.2032 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 16 | Капиталь ремонт 2033 | 01.01.2018-31.12.2033 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 17 | Капиталь ремонт 2034 | 01.01.2018-31.12.2034 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 18 | Капиталь ремонт 2035 | 01.01.2018-31.12.2035 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 19 | Капиталь ремонт 2036 | 01.01.2018-31.12.2036 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 20 | Капиталь ремонт 2037 | 01.01.2018-31.12.2037 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 21 | Капиталь ремонт 2038 | 01.01.2018-31.12.2038 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 22 | Капиталь ремонт 2039 | 01.01.2018-31.12.2039 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 23 | Капиталь ремонт 2040 | 01.01.2018-31.12.2040 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 24 | Капиталь ремонт 2041 | 01.01.2018-31.12.2041 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 25 | Капиталь ремонт 2042 | 01.01.2018-31.12.2042 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |
| 26 | Капиталь ремонт 2043 | 01.01.2018-31.12.2043 | Программа буенча сумма | Млн. сум | 100% | +/- |

## 9. Программага үзгәрешләр кертү тәртибе

Программа кимендә елга бер тапкыр актуальләштерелергә тиеш.

Программаны актуальләштерү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- Программага кертелгән күп фатирлы йортларны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә һәм реконструкцияләнергә тиешле дип тану;
- Программага кертелгән күп фатирлы йорт урнашкан җир участогын дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алуны һәм шундый күп фатирлы йорттагы һәр торак бүлмәне алуны Законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыру;
- күп фатирлы яңа йортларны файдалануга тапшыру;
- Программага кертелгән күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге үзгәрү;
- Программага кертелгән күп фатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү сроклары үзгәрү;
- Программага үзгәрешләр кертүгә сәбәп булырлык башка нигезләр.

Күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау срогын соңрак чорга күчерү, күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча планлаштырылган хезмәт һәм (яки) эш төрләренең исемлеген кыскартуны күздә тотучы үзгәрешләрне Программага кертү, тиешле карар булган очракта, законда билгеләнгән тәртиптә торак милекчеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2018 елның 29 мартындагы 1692 нче
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә урнашкан күп фатирлы йортлардагы
гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча
муниципаль адреслы программага
1 нче кушымта

Программаның максатлары, бурычлары, бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары, еллар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор ларның зурлыгы, ел | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2018 база | 2019 | 2018 ел база | | 2019 ел | |
| Шәһәрнең күп фатирлы йортларындагы гомуми мөлкәткә үз вакытында һәм сыйфатлы капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итү | Халыкка капиталь ремонт үткәрү сроклары, төрләре, күләмнәре һәм кагыйдәләре турында хәбәр итү | Идарәче компанияләр, генподрядчы оешмалар | 2018-2043 | Милекчеләр нең үткәрелгән җыелыш лары саны | 113 | 136 | Федераль бюджет | 0,00 | Федераль бюджет | 0,00 |
| | | | | | | | Республика бюджеты | 0,00 | Республика бюджеты | 0,00 |
| | | | | | | | Шәһәр бюджеты | 0.00 | Шәһәр бюджеты | 0,00 |
| | | | | | | | Башка чыганаклар | 0,00 | Башка чыганаклар | 0,00 |
| | | | | | | | Барлыгы | 0,00 | Барлыгы | 0,00 |
| | Торак фондның техник торышын анализлау | Яр Чаллы шәһәренең идарәче компанияләре , генподрядчы оешмалар | 2018-2043 | Биналарны тикшерү саны | 113 | 136 | Федераль бюджет | 0.00 | Федераль бюджет | 0,00 |
| | | | | | | | Республика бюджеты | 0,00 | Республика бюджеты | 0.00 |
| | | | | | | | Шәһәр бюджеты | 0,00 | Шәһәр бюджеты | 0,00 |
| | | | | | | | Башка чыганаклар | 0,00 | Башка чыганаклар | 0,00 |
| | | | | | | | Барлыгы | 0,00 | Барлыгы | 0,00 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Энергия ресурсларын куллануның энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү | Энергетика нәтиҗәлелеге технологияләрен кертү | Идарәче компанияләр | 2018-2043 | Фасадларга капиталь ремонт ясалган йортлар саны | 57 | 51 | Федераль бюджет | 0,00 | Федераль бюджет | 0,00 |
| | | | | | | | Республика бюджеты | 130701048,03 | Республика бюджеты | 115740953,21 |
| | | | | | | | Шәһәр бюджеты | 125139332,70 | Шәһәр бюджеты | 103924274,39 |
| | | | | | | | Башка чыганаклар | 154428743,17 | Башка чыганаклар | 199707330,77 |
| | | | | | | | Барлыгы | 410 269 123,90 | Барлыгы | 329 372 558,37 |
| | Чыдам материаллар һәм ресурс саклау технологияләрен кулланып капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник карарлардан һәм комплекслылыктан файдалану | Идарәче компанияләр | 2018-2043 | Капиталь ремонт ясалган йортлар саны | 113 | 136 | Федераль бюджет | 0,00 | Федераль бюджет | 0,00 |
| | | | | | | | Республика бюджеты | 303 652 750,00 | Республика бюджеты | 297 745 612,00 |
| | | | | | | | Шәһәр бюджеты | 267 347 000,00 | Шәһәр бюджеты | 267 347 000.00 |
| | | | | | | | Башка чыганаклар | 839 536 966,64 | Башка чыганаклар | 673 064 936.51 |
| | | | | | | | Барлыгы | 1410536716,64 | Барлыгы | 1238157 548.51 |
| Торак-коммуналь хуҗалыгы сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсен күтәрү | Торак фондның эстетик җәлеп итүчәнлеген арттыру | Идарәче компанияләр, шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | 2018-2043 | Фасадларга капиталь ремонт ясалган йортлар саны | 57 | 51 | Федераль бюджет | 0,00 | Федераль бюджет | 0,00 |
| | | | | | | | Республика бюджеты | 130701048,03 | Республика бюджеты | 115740953,21 |
| | | | | | | | Шәһәр бюджеты | 125139332,70 | Шәһәр бюджеты | 103924274,39 |
| | | | | | | | Башка чыганаклар | 154428743,17 | Башка чыганаклар | 199707330,77 |
| | | | | | | | Барлыгы | 410269123,90 | Барлыгы | 329 372 558,37 |
| | Халыкның аз мобильле төркемнәре өчен уңайлы шартлар тудыру | Идарәче компанияләр, район хакимиятләре | 2018-2043 | Лифтларга, подъездлар га капиталь ремонт ясалган йортлар саны | 27 | 34 | Федераль бюджет | 0,00 | Федераль бюджет | 0,00 |
| | | | | | | | Республика бюджеты | 69621269,01 | Республика бюджеты | 85299843,93 |
| | | | | | | | Шәһәр бюджеты | 50832413,96 | Шәһәр бюджеты | 81301654,39 |
| | | | | | | | Башка чыганаклар | 87185121,03 | Башка чыганаклар | 172437483,3 |
| | | | | | | | Барлыгы | 207638804,00 | Барлыгы | 339038981,62 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Куркынычсыз яшәү шартларын тәэмин итү | Идарәче компанияләр, генподрядчы оешмалар | 2018-2043 | Янгынга каршы автоматика системасына капиталь ремонт ясалган йортлар саны | 3 | 0 | Федераль бюджет | 0,00 | Федераль бюджет | 0,00 |
| | | | | | | | Республика бюджеты | 2300000 | Республика бюджеты | 0,00 |
| | | | | | | | Шәһәр бюджеты | 2100000 | Шәһәр бюджеты | 0,00 |
| | | | | | | | Башка чыганаклар | 3250000 | Башка чыганаклар | 0,00 |
| | | | | | | | Барлыгы | 7650000 | Барлыгы | 0,00 |